# ТӨЙМӘ

Бигрәк авыр фән шул ядро физикасы. Протон, нейтрон, чурт-чураман — берсе дә Ләмзиянең башына керми. Экзаменда яначак Ләмзия. Анысы инде көн кебек ачык.

Юк, Ләмзиягә экзаменны «провалить» итәргә ярамый. Ничек тә рәтен табарга кирәк.

Әле менә тагы шул фәннән лекция бара. Бу семестрда соңгы лекция. Ләмзия, игътибарын тупларга теләп, профессорга карый. Профессоры нинди бит әле! Кара костюм кигән була. Ә материалы кыйммәтлегә охшый. Метры утыз сум да илле тиенлек. Әйе, әйе, нәкъ шулай. Ләмзия теләсә кем белән бәхәсләшергә әзер. Кичә генә универмагта үзе күрде. Материалы яхшы да бит, тик менә пинжәге... Ике бортлы. Хәзер андый фасон модада түгел. Әһә, бер төймәсе төшкән. Ә нигә хатыны такмый икән? Ирен карамаган нинди хатын ди ул? Профессор кешегә бер төймәсе төшкән пинжәк киеп йөрү килешми бит инде. Буйдак булса, бер хәл. Хәер, буйдак булуы да мөмкин. Әйтик, хатыны үлгән... Юк, аерылышканнар алар. Характерлары туры килмәгән. Профессор көне буе эштә. Ә хатыны — чүпрәк колы. Кибетләргә чаба. Ахирәтләренә йөри. Егетләр белән чуала. Шуңа профессор ничек чыдап торсын? Аерып җибәрә, әлбәттә. Һәм менә килеп... буйдак. Шулай булмаса, төймәсез йөрмәс тә иде.

Буйдак профессор...

Ләмзия аны кабаттан тикшереп, үзенчә бәяләп чыкты.

Болай ярыйсы гына. Урта яшьләрдә. Күз төпләрендә җыерчыклар бар-барлыкка. Аның каравы күзләре нинди! Бөркетнекемени! Зәңгәр күзләр. Диңгез суы кебек зәңгәр. Ләмзиянең диңгезне күргәне юк югын, шулай да аның художникларга ышанмаска бертөрле дә нигезе юк. Алар бит диңгезне гел зәңгәр итеп төшерәләр. Зәңгәр диңгез... Зәңгәр күзләр... Ләмзиягә зәңгәр күзле ирләр ифрат ошый. Менә профессорның да күзләре зәңгәр булып чыкты. Тик чәчләре генә сирәк. Янәшә барганда, аерма шунда ук кешеләрнең күзләренә ташланачак. Ләмзиянең чәчләре күпереп тора. Хәтта бераз бөдрә дә.

Хәер, анысы парикмахерның тырышлыгы. Читтән карап торучылар аны кайдан белсеннәр?! Табигать шулай яраткан диләр инде алар. Күпереп торган бөдрә чәчле кыз белән чәче коелып беткән профессор атлый... Һем... Бигүк килешеп бетми түгелме соң? Хәзер бит химия заманы. Синтетик чәч куйдырып була лабаса! Әлбәттә, була. Бу мәсьәлә хәл ителде. Аның ире синтетик чәчле булачак. Ә ул чәчнең төсен Ләмзия үзе сайлаячак.

Шулай итеп, профессор чәчле дә булды. Менә алар «Волга»да китеп баралар. Профессор машинасыз булмас бит инде. Руль артында — Ләмзиянең синтетик чәчле ире. Янәшәдә — ул. Юк, киресенчә. Профессор Ләмзиянең урынында, ә Ләмзия машинаны үзе алып бара. Әйбәт бит! Урамда кешеләр аңа сокланып торып калалар. Нинди чибәр кыз машина йөртә, диләр. Араларында зәңгәр күзле егетләр дә бар. «Үзе нинди яшь тә, матур да, тик менә ире генә картрак». Монысын инде баягы зәңгәр күзле егетләр әйтәчәк. Дөрес сүзгә җавап юк. Картрак шул. Ләкин Ләмзия барыбер аннан котылу юлын табачак. Ядро физикасына башы эшләмәсә дә, дөнья мәсьәләләрендә аның белән ярышырлык кеше юк хәзергә. Картлач профессор белән аерылышырга да күп сорамас ул. Ә суд мөлкәтне икегә бүләчәк. Машинаны исә Ләмзия үзенә калдырачак, моңа шикләнергә дә ярамый. Шулай итмәсә, Ләмзия Ләмзия буламыни!

Менә ул профессор белән аерылган. Әкрен генә «Волга»да бара. Күзләре боек аның. Кешеләр: «Бу хатын кайгылы чагында да чибәр икән», — дип уфтанып калалар. «Берәр бәхетсезлеккә юлыккандыр», — диеп кызганып та куялар. Тукта! Нигә үзен кызгандырып торырга тиеш әле ул? Юк, Ләмзия елмая. Ара-тирә яңгыравыклы тавыш белән көлеп тә җибәрә. Ә нигә көлә әле ул? Әһә, янында зәңгәр күзле егет утыра. Алар урам читендә «Волга»ның үткәнен күзәтеп торган профессорга карап, икәүләшеп көләләр. Профессорның хәзер синтетик чәче юк. Ләмзия белән аерылышу кайгысыннан эчеп, ул унбиш тәүлеккә эләккән. Ә унбиш тәүлеккә эләккән кешеләрнең чәчен ни эшләтүләре билгеле инде — кыралар. Такыр башлы профессор бик кызганыч хәлдә: тагын да картаеп киткән. Өс-башына да игътибар итми, Ләмзия тагып биргән элекке төймәсе тагын төшкән. Менә бит хатын-кыз хәстәре булмавы нишләтә ирләрне...

Ләмзиянең уйларын звонок бүлдерде. Профессор лекциясенең соңгы җөмләсен әйтте дә өстәлдәге язуларын алырга үрелде. Шулчакта пинжәген каптырды.

Бәй, бу ни хикмәт?! Төймә төшмәгән бит! Тик каптырылмаган гына булган. Юк, болай булгач, экзаменда яначак Ләмзия. Мотлак, яначак.

Ә лекцияне ул бу юлы да аңламады. Ни әйтсәң дә, катлаулы фән шул ядро физикасы…

*1964*

## САРЫ САРАФАН

Бәрәңге салынган сумканы бер кулдан икенче кулга алмаш-тилмәш күчереп, акрын гына базардан кайтып киләм. Үзем шәһәр әһелләренең тетмәсен тетәм.

Тапканнар базар ясар урын! Җәһәннәм төбендә ята. Һич кайтып җитеп булмый. Кояш әнә кайда ук күтәрелеп өлгергән. Элеккесе базар иде, ичмасам. Өйдән илле метр киттең – базар. Базардан чыгып, илле метр киттең – өй. Җаныңа рәхәт иде. Ә хәзер йөре инде, ярты көн сумка күтәреп. Минем яшьтәге кешегә бик җиңелдән түгел. Яшьләргә генә ул, көне-төне чапсалар да, чурт та булмый. Әнә берсе килә. Сары сарафанын җилфердәтә генә. Ничек атлый бит әле, ә! Йөзәмени! Йөзеннән, бөтен торышыннан тирә-якка ниндидер сихри нур сибелә кебек. Шул нурдан бар нәрсә уяна кебек. Әйтеп-аңлатып бетерерлек түгел. Фәрештә инде, торганы белән фәрештә!

Арыганлык әллә кая югалды. Сумка да җиңеләеп киткәндәй булды. Була бит дөньяда шундый матурлык! Сөбханалла! Шул кыз артыннан ияреп киткәнемне сизми дә калдым. Үземне үзем тиргим: карт иблис, сиңа ни җитмәгән тагын? Кире борыл! Үземә шундый команда бирәм. Эш команда бирүдәмени, аяклар тыңламагач. Кире якка атлыйлар да атлыйлар. Ә күзләрне баягы фәрештәнең сарафаныннан аерып алып булмый. Ай әттәгенәсе! Югалды сарафан, портфель тоткан берәү каплады. Гәүдәсе гәүдәме! Филдән ким түгел. Базар урамыннан йөрмәсә, беткәнмени аңа башка урам? Кыяфәтенә караганда, зур гына урында эшләгән кешегә охшый. Машинасы гаражда торадыр әле, ә ул җәяү йөри, янәсе. Шәплеген күрсәтә. Юк инде, тәпи-тәпи атлауларны онытканың күренеп тора. Әнә ничек тиреңне сөртәсең. Хәзер узып китәбез сине. То-то! Уздык. Базарны да уздык. Алда янә сарафан. Күңел яңадан күтәрелде. Теге портфельле кешегә дә ачу бетте.

Хәтта үзен кызганып та куйдым. Элек берәр түрә булган да, урынынан очырганнардыр, мөгаен. Машинасын да алганнардыр. Шуңа күрә җәяү йөрергә мәҗбүр... Сөбханалла! Машалла! Аяклары нинди бит, ә! Пушкин хатын-кыз аякларын юкка гына мактамаган икән. Тфү! Анавы күзлекле колгага ни калган тагын, шулкадәр чапмаса. Янә сарафанны күздән яздырды. Марафон йөгерешендә катнаша диярсең. Күзлеге төшеп ватылгыры! То-то! Абынды. Күзлеге дә төшеп китте. Хәзер аны бер сәгать эзли инде. Эзләсен, эше ул кадәр ашыгыч түгелдер әле... Әлеге Пушкинны әйтәм, дурак булмаган, ә! Ай, кадалгыры! Күзлеген тапкан тәки. Тагын сарафанны каплады. Ә портфель тоткан типны корт чакканмыни, мине узмакчы була. Карашын алга төбәгән. Киләчәккә карый, янәсе. Артист! Кабинетында хезмәткәрләре алдында уйнап өйрәнгән, урамда да шул гадәтен куа. Әлләү! Кемдер аякка басты. Дагалы ботинка белән.

— Гафу итегез!

Мыегы да чыкмаган егет, кешеләрне ерып дигәндәй, алга омтыла. Менә бит нинди хәзерге яшьләр. Өлкән димиләр, ни димиләр, сөмсез сыер кебек кереп киләләр. Ярый әле, монысы гафу үтенә белә, бозылып бетмәгән, күрәсең.

Әлләү! Арттан кайсысыдыр җилкәгә нык кына бәрелеп узып китте. Әдәпсезләр! Сарафанны бөтенләй капладылар. Әле алда аз гына булса да күренеп кала иде... Туктагыз, агаегыз ул кадәр карт түгел лә. Яшь чагында аны узучылар сирәк була торган иде. Күрсәтер әле ул сезгә!

Бер төркем кешеләр арасыннан үземә юл сала-сала, иң алгы рәткә килеп чыктым. Алан-йолан карыйм. Кайда теге кыз? Кайда булды?

Уң якта бәләкәй генә капка шыгырдады. Борылып карасам, ни күрәм: сары сарафанның итәге, мине үчекләгәндәй, бер җилпенде дә капка эченә кереп югалды.

Кинәт авыраеп киткән сумканы уң кулдан сул кулга күчереп тоттым да кире борылдым. Портфельле түрә дә, күзлекле колга да, дага табанлы ботинка кигән егет тә, аркага бәрелеп киткән бәндә дә — барысы да ашыкмый гына кирегә атлыйлар иде...

Мин дә әкрен генә атлыйм. Базар, чынлап та, ерак икән шул. Төш җиткән, ә минем һаман кайтып җитә алганым юк. Менә элекке базар базар иде, ичмасам, рәхәт иде. Ә хәзер бер сумка бәрәңге өчен йөр инде. Минем яшьтәге кешегә шулкадәр араны үтү уен эш түгел, ни генә дисәң дә.

*1965*

# ШУНДЫЙ ДУСЛЫК

Берьюлы ике авыздан бер үк сүз чыкты:

— Кемне күрәм мин!

Дуслар кочаклаштылар. Аларның бер-берсен күрмәгәннәренә биш былтыр иде.

— Урамда басып тору килешмәс. Әйдә, булмаса, берәр җиргә, — диде дусларның берсе.

— Киттек. Җайлап сөйләшеп тә утырырбыз, — дип хуплады аның тәкъдимен икенчесе.

Алар, ресторанга кереп, сырага заказ бирделәр. Ике арада шундый сөйләшү башланды:

— Йә, сөйләп җибәр, эшләр ничек?

— Менә шулай инде.

— Да… Шулай дисең инде?

— Әйе. Шулайрак шул.

Уңайсыз тынлык урнашты. Дусларның берсе, ресторанга кереп утырырга димләгәне, бу тынлыкны бозарга барлык егәрлеген салды:

— Димәк, эшләр шулайрак, дисең инде. Яраган, яраган. Шулай булганы яхшы аның. Менә минем үземнең дә эшләр шулайрак тора.

Тегесе дә башланган әңгәмәне туктатмаска тырышты:

— Үзгәрмәгәнсең тәки. Элек тә эшне шулайрак йөртә торган идең.

— Ха-ха-ха! Шулай дисең инде?

— Әйе, шулай дим шул. Шулай булгач, ничек итәсең.

Тагы сүз бетте. Һәр ике тараф, инде нәрсә турында сорашырга дип, киеренке рәвештә баш вата башлады. Бергә үткән балачакны искә төшерер идең, ул күптән онытылып беткән. Эш хакында сорашыргамы? Алай дисәң, дуслар хәзер бер-берсенең кайда яшәгәнлекләрен дә белмиләр. Ә белмәгәнне белдерү уңайсыз лабаса!

Ярый әле, официант кыз сыра китерде.

Дуслар җанланып китте. Сыра савытлары бушады, әмма тел ачкычы табылмады.

— Әнә теге якта кичә янгын булды бугай, — дип ымлап куйган булды берсе.

— Янгын дисеңме?

— Әйе, янгын.

— Берәр нәрсәгә ут капкан инде, алайса, — шулай дип җөпләде иптәшенең сүзен икенчесе, бу сүзләргә тирән мәгънә салып.

Сүз тагын бетте. Дуслар «ак»ны алдырдылар. Бәлки, тел ачкычын ул бирер?